**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №157-24 «25» октябрь 2023 ел

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советының 2017 елның 29 сентябрендәге 63-18 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрен төзелешен проектлау нормативлары турында»гы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрен төзелешен проектлау нормативларына үзгәрешләр кертү хакында (13.12.2018 №120-29, 23.05.2019 №137-33, 20.08.2019 №144-35, 22.10.2019 №151-36, 12.12.2019 №156-38, 12.03.2020 №164-41, 25.06.2021 №40-9, 12.10.2022 №100-18 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 438-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының
Азнакай шәһәре Советы **карар кабул итте**:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советының 2017 елның 29 сентябрендәге 63-18 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрен төзелешен проектлау нормативлары турында»гы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрен төзелешен проектлау нормативларына (13.12.2018 №120-29, 23.05.2019 №137-33, 20.08.2019 №144-35, 22.10.2019 №151-36, 12.12.2019 №156-38, 12.03.2020 №164-41, 25.06.2021 №40-9, 12.10.2022 №100-18 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.1.12 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.12. Территориаль зоналар чикләре муниципаль берәмлекләр, торак пунктлар, җир кишәрлекләре чикләрен кисеп үтә алмый (Россия Федерациясе Җир кодексында яисә башка федераль законда каралган очракларда чикләре территориаль зоналар чикләрен кисеп үтә ала торган җир кишәрлегеннән тыш). Мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләреннән, федераль әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләреннән, Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләреннән файдалануның махсус шартлары булган территориаль зоналар чикләре белән кисешү рөхсәт ителә».

2. Әлеге карар 01.02.2024 елның үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны торак-коммуналь хуҗалыгы, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин